СОВЕТ
ЯЛКЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЯЛКЫН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.06. 2019 д.Ялкын № 100

**Алексеевск муниципаль**
**районы Ялкын авыл җирлеге Советының**
**“Җир салымы турында”гы**
**16 ноябрь, 2018 ел, 79 нче**
**Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Тиешле законнарга, шул исәптән “Россия Федерациясе Салым кодексынының икенче өлешенә үзгәрешләре кертү турында”гы 15 апрель, 2019 ел, 63-ФЗ санлы Федераль законның 1 нче маддәсенә, 23 пунктына һәм “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законның 9 нчы маддәсенә туры китерү максатында

**Ялкын авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Җир салымы турында”гы 16 ноябрь, 2018 ел, 79 нче Карарына түбәндәге эчтәлектәге үзгәреш кертергә:

2 нче пункт, 2 нче пунктчаның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), шулай ук “Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 29 июль, 2017 ел, 217-ФЗ санлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләрен”

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, ләкин ул Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында басылып чыкканнан соң бер айдан да кимрәк булмаган срокта үз көченә керә.

3. Әлеге Карар үз көченә кергән вакыттан алып Ялкын авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында”гы карары һәм “2018 елга кадәр кабул

ителгән   әлеге карарларга  үзгәрешләр кертү турында”гы карарларны көчләрен югалткан, дип санарга.

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

Алексеевск муниципаль районының
**Ялкын авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.В.Гущина**